ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСАНСУПОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСӘНСЕФ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*423988, Р.Т. Муслюмовский район, д.Татарское Булярово, ул.Молодежная 12,тел.(8-85556) 3-40-37*

*Тат.Буләр авылы* *15.март 2019*

# КАРАР № 9

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 7 маддәсе нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, юлларны һәм күперләрне саклауны кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Исәнсеф авыл җирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия төзү.
2. Исәнсеф авыл җирлеге территориясендә 4 кешедән торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзергә һәм 2019 елгы язгы ташу чорында Исәнсеф авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын расларга.
3. Исәнсеф авыл җирлеге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерүне һәм икътисад объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

   - Исәнсеф авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгы, язгы ташуга каршы комиссия утырышларында икътисад объектларының куркынычсызлыгы, язгы ташу суларының авариясез үтүен тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
   - язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә игътибар бирү һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын ачыклау. Көч һәм чаралар турында мәгълүматлар җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен тикшереп тору;
   - елга һәм буаларда, саркофагларсыз үләт базлары янында су дәрәҗәсен тәүлек буе күзәтү өчен вакытлыча постлар оештырырга; - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
   - язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерүне тәэмин итәргә;
   - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән саклау буенча чараларның үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Исәнсеф авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Сахбутдинова Ф.Т.**

Мөслим муниципаль районы
Исәнсеф авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесене
«15» март, 2019 ел,
9 нче санлы Карарына
1нче кушымта

**Исәнсеф авыл җирлеге буенча**
**гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне тәэмин итү комиссиясе**

1. Исламов Илсур Магуфурзянович
2. Изибаева Аниса Алжбертовна
3. Вазетдинов Илдар Имаметдинович
4. Сафин Расих Рифович

**Исәнсеф авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Сахбутдинова Ф.Т.**